РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы,
Азнакай районы, 423310

Тел.(885592)43-2-37; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» ноябрь 2023 ел. № 40

Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Әсәй авылы, Үзәк урам адресы буенча урнашкан 16:02:200101:57 кадастр номерлы җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча Әсәй авыл җирлегендә яшәүчеләрнең яшәү шартлары, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре уңай шартларын үтәү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Әсәй авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирә:

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Югары Әсәй авылы, Үзәк урам адресы буенча урнашкан 1071,14 кв.м.мәйданлы 116:02:200101:57 кадастр номерлы булган җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләргә. - Элемтә хезмәтләре күрсәтү (код 13.1) - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1).
2. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын оештыручы итеп - Әсәй авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне;
- үткәрү вакыты - 2023 елның 16 ноябреннән 2023 елның 30 ноябренә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны - Әсәй авыл җирлегенең Мәдәният йорты бинасы, адресы: Әсәй авылы, Үзәк урам, 38Г йорт.
- 2023 елның15 ноябренә кадәр тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма

тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Азнакай

муниципаль районы Әсәй авылы, Үзәк урам, 38Б, Азнакай муниципаль районының Әсәй авылы җирлеге Башкарма комитеты.

3. Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 30 ноябренә кадәр җир кишәрлеге белән гомуми чикләре булган җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртүгә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турындагы хәбәрләрне җибәрергә;

- җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында нәтиҗә әзерләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: Г.З. Дәминова